ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**КАРАР**

№ 7 23.09.2025 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. М. Мингуловның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставының 44 статьясындагы 4 өлешенә таянып, район территориясендә хакимият структураларының эшләвен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы:

1. Зайцев Станислав Юрьевичны конкурс нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләп куелганчы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 23 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга (aksubayevo.tatarstan.ru).

Аксубай муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе: А.М. Мингулов